РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 26 нчы сентябре** **Чистай шәһәре** **№ 47/7**

Татарстан Республикасы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең жирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

“Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексына таянып, Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлегенең жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә:

- территориаль саклау һәм гражданнар оборонасы, халыкны һәм жирлек территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;
- жирлек территориясендә авария-коткару хезмәтләрен булдыру, карап тору һәм оештыру.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетына:

- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру буенча, Чистай шәһәре Башкарма комитеты белән килешү төзергә;
- әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру буенча килешү имзалаганнан соң, билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
район башлыгы Д.А. Иванов